**Муниципаль юнәлештәге мәсьәләләр буенча үзара хезмәттәшлек турында норматив хокукый актлар һәм алар турында Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары белешмәләре регистры хакында килешү**

2018 елның 01 феврале                                        Әгерҗе шәһ., ТР

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Уставы нигезендә эшләүче Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгы Макаров Валерий Владимирович, алга таба «район башлыгы» дип аталачак, бер яктан, һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге Уставы нигезендә эш итүче Кодаш авыл җирлеге башлыгы Шакиров Фәнис Миннефлюрович, икенче яктан, алга таба «җирлек башлыгы» дип аталачак, бергә «Яклар» дип аталачак, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (алга таба - 14-ТРЗ номерлы Закон) «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (алга таба - 14-ТРЗ номерлы Закон) гамәлгә ашыру максатларында, түбәндәге Килешүне төзеделәр:

## 1. Килешү предметы

Килешү предметы булып муниципаль норматив хокукый актларны җыю һәм җибәрү мәсьәләләре буенча район башлыгының һәм җирлек башлыгының үзара эшчәнлеген оештыру һәм алар турында 14-ТРЗ номерлы 5 Законның  статьясында билгеләнгән белешмәләрне (алга таба шулай ук - документлар) 92-ТРЗ номерлы Законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына (алга таба шулай ук - регистр) җибәрү тора.

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Район башлыгы җирлек башлыгыннан документлар кабул итүне һәм аларны 14-ТРЗ номерлы закон белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда регистрга җибәрүне тәэмин итә.

2.2. Җирлек башлыгы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән нормалар һәм таләпләр нигезендә документлар рәсмиләштерү;

регистрга кертү өчен җибәрелә торган документларның тулылыгы һәм 14-ТРЗ номерлы закон белән билгеләнгән белешмәләрнең дөреслеге;

район башлыгының 2016 елның 26 гыйнварындагы 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне җыю һәм җибәрү буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеге регламенты нигезендә билгеләнгән район башлыгына яисә җирле үзидарә органына (вазыйфаи затына) документлар тапшыру.

**3. Килешүнең гамәлдә булу вакыты**

3.1. Килешү бер елга төзелгән, Яклар тарафыннан имзаланган вакыттан үз көченә керә һәм 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3.2. Әгәр Якларның берсе дә Килешүнең 3.1 пунктында каралган срок тәмамланырга ике ай кала өзелү турында белдермәсә, Килешү бер календарь елга озайтылган дип санала.

**4. Килешүне туктату нигезләре һәм тәртибе**

Әлеге Килешү вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

Яклар килешүе буенча;

Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта.

**5. Якларның җаваплылыгы**

Килешүнең шартларын Яклар тарафыннан үтәмәү яки тиешенчә үтәмәү бер яклы мөнәсәбәтләрне өзү өчен нигез булып тора.

**6. Йомгаклау нигезләмәләре**

6.1. Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Якларның үзара ризалыгы буенча кертелә һәм өстәмә килешү белән язма рәвештә рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

6.2. Килешү Якларның һәркайсы өчен берәр нөсхәдә тигез юридик көчкә ия, ике нөсхәдә төзелгән.

**7. Якларның имзалары**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгы

_______________ В.В. МАКАРОВ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге башлыгы

_____________ Ф.М. ШАКИРОВ